**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 11 октябре
№ 2435-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1488. «Россия Федерациясенең кайбер закон актларына «112» бердәй номер буенча ашыгыч оператив хезмәтләр чакыруны тәэмин итү системасын булдыру өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 120799-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясе территориясендә «112» бердәй номер буенча ашыгыч оператив хезмәтләр чакырудан файдалану мәсьәләләрен норматив җайга салуның бер рәвешле алымын тәэмин итү турында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясенең кайбер закон актларына «112» бердәй номер буенча ашыгыч оператив хезмәтләр чакыруны тәэмин итү системасын булдыру өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 120799-6 номерлы федераль закон проектын (Россия Федерациясе территориясендә «112» бердәй номер буенча ашыгыч оператив хезмәтләр чакырудан файдалану мәсьәләләрен норматив җайга салуның бер рәвешле алымын тәэмин итү турында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 11 октябре
№ 2436-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1489. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Курган өлкә Думасының закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Курган өлкә Думасының закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Курган өлкә Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 11 октябре
№ 2437-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1490. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 96781-6 номерлы федераль закон проекты турында (вазыйфаи затлар тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибен бозган өчен җаваплылыкны көчәйтү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 96781-6 номерлы федераль закон проектын (вазыйфаи затлар тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибен бозган өчен җаваплылыкны көчәйтү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 11 октябре
№ 2438-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1491. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 6.17 статьясына үзгәреш кертү хакында» 112058-6 номерлы федераль закон проекты турында (административ хокук бозулар составын төгәлләштерү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 6.17 статьясына үзгәреш кертү хакында» 112058-6 номерлы федераль закон проектын (административ хокук бозулар составын төгәлләштерү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 11 октябре
№ 2439-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1492. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 4.5 һәм 28.7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 100313-6 номерлы федераль закон проекты турында (азартлы уеннарны оештыру һәм үткәрү турындагы законнарны бозган өчен административ җаваплылыкка тарту вакыты хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 4.5 һәм 28.7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 100313-6 номерлы федераль закон проектын (азартлы уеннарны оештыру һәм үткәрү турындагы законнарны бозган өчен административ җаваплылыкка тарту вакыты хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 11 октябре
№ 2440-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1493. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 103010-6 номерлы федераль закон проекты турында (арбитраж идарәчеләрнең үз-үзен җайга сала торган оешмасы тарафыннан бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турындагы законнарда билгеләнгән бурычларын үтәмәгән өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 103010-6 номерлы федераль закон проектын (арбитраж идарәчеләрнең үз-

үзен җайга сала торган оешмасы тарафыннан бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турындагы законнарда билгеләнгән бурычларын үтәмәгән өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 11 октябре
№ 2441-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1494. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 30.5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 101827-6 номерлы федераль закон проекты турында (административ кулга алу хакындагы карарга шикаять карау срокларын төгәлләштерү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 30.5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 101827-6 номерлы федераль закон проектын (административ кулга алу хакындагы карарга шикаять карау срокларын төгәлләштерү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 11 октябре
№ 2442-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1495. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 23.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 105558-6 номерлы федераль закон проекты турында (суд органнарының башкарма хакимият органнары белән мөнәсәбәтләре өлкәсендәге эшчәнлеген оптимальләштерү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 23.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 105558-6 номерлы федераль закон проектын (суд органнарының башкарма хакимият органнары белән мөнәсәбәтләре өлкәсендәге эшчәнлеген оптимальләштерү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 11 октябре
№ 2443-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1496. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Х.Г. Миргалимовның депутат гарызнамәсе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Х.Г. Миргалимовның кечкенә торак пунктлар һәм бакчачылык ширкәтләре юлларын һәм аларга керү юлларын инвентаризацияләү зарурлыгы турындагы гарызнамәсен Та-

тарстан Республикасы Премьер-министры И.Ш. Халиковка җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 11 октябре
№ 2444-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1497. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз дүртенче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утыз дүртенче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Ефимов Евгений Петровичның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты составындагы үзгәреш турында.

3. Яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру, сәламәт яшәү рәвешен булдыру һәм Казан шәһәрендә уздырылачак 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасын әзерләүгә ярдәм итү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе составындагы үзгәреш турында.

4. «2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 3420-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

5. «2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 3421-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

6. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 1407-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

7. «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2391-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

8. «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 4416-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

9. «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 6398-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

10. «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүдә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 6408-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

11. «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 5417-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

12. «Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу тәртибе турында» 1434-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

13. «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 2425-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 4427-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

15. «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү федераль фондының эконом класслы торак төзелеше өчен, шул исәптән мондый торак төзү максатларында аларны комплекслы үзләштерү өчен түләүсез вакытлыча файдалануга яисә арендага тапшырылган җир кишәрлекләрендә төзелгән яисә төзелеп килүче эконом класслы торакны сатып алу хокукына ия гражданнар исемлекләрен төзү кагыйдәләре турында, әлеге гражданнарны

шушы исемлекләргә кертү тәртибе һәм чиратлылыгы турында» 4424-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

16. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 5432-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

17. «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законының 92 статьясына үзгәреш кертү хакында» 5433-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

18. «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 5437-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

19. Татарстан Республикасы административ-территориаль берәмлекләренә исем бирү һәм аларның исемнәрен үзгәртү турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан карау хакындагы нигезләмәнең 18 пунктына үзгәрешләр кертү турында.

20. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты составындагы үзгәреш турында.

21. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты составындагы үзгәреш турында.

22. Профессиональ даими нигездә эшләү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатын сайлау турында.

23. «Өстенлекле милли проектларны гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссияләре төзү турында» 2006 елның 30 мартындагы 2154-III ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 22 апрелендәге 84-IVДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән расланган Сәламәтлек саклау өлкәсендә милли проектны гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе составындагы үзгәреш турында.

24. «Муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссияләре әгъзаларын билгеләү турында» 2010 елның 23 сентябрендәге 1127-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарының 1 пунктына үзгәрешләр кертү хакында.

25. 2012 елның гыйнварыннан октябренә кадәрге чорда полиция эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министры А.В. Хохорин хисабы.

26. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 121965-6 номерлы федераль закон проектына төзәтмәләр хакында.

27. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12.36.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Новосибирск өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

28. «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы – Корылтаеның закон чыгару инициативасы хакында.

29. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 381 статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Амур өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында.

30. «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 52050-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

31. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясына һәм «Сочи шәһәрендә 2014 елда XXII Кышкы олимпия уеннарын һәм XI Кышкы паралимпия уеннарын оештыру һәм үткәрү, тау климаты курорты буларак Сочи шәһәрен үстерү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 14 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 109201-6 номерлы федераль закон проекты турында (проект документациясенә карата дәүләт экспертизасы үткәрелә торган объектлар исемлеген арттыру өлешендә).

32. «Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 259 статьясына үзгәреш кертү турында» 136086-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 259 статьясының икенче өлешендә каралган гарантияләрнең ундүрт яшькә кадәрге балаларны ireннән (хатыныннан) башка тәрбияләүче аналарга һәм аталарга кагылу өлешендә).

33. «1941 – 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы чорында зыян күргән гражданнарга социаль ярдәм чаралары турында» 40717-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

34. «Ерак Себер районнарында һәм аларга тиңләштерелгән җирләрдә эшләүче һәм яшәүче затлар өчен дәүләт гарантияләре һәм компенсацияләр турында» Россия Федерациясе Законының 34 статьясына үзгәреш кертү хакында» 138744-6 номерлы федераль закон проекты турында (Ерак Себер районнарында һәм аларга тиңләштерелгән җирләрдә эшләүче һәм яшәүче, тәрбиягә бала алган гаилә турында шартнамә буенча балага яисә балаларга опеканы яки попечительлекне гамәлгә ашырып, башка түләүле эшчәнлекне башкармыйча картлык һәм инвалидлык буенча хезмәт пенсияләрен алучы пенсионерларга Россия Федерациясе территориясендә ял итү урынына барып кайту хакын эшләмәүче пенсионерларга түләгән кебек түләү чыгымнарын компенсацияләү хокукын бирү турында)

35. «Россия Федерациясендә 2018 елда футбол буенча ФИФА дөнья чемпионатын, 2017 елда ФИФА Конфедерацияләре кубогын әзерләү һәм үткәрү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 142750-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

36. «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 146690-6 номерлы федераль закон проекты турында (гражданнарны эш белән тәэмин итү категориясенә кертү критерийларын төгәлләштерү хакында).

37. Көндез укучы балигъ булмаган балаларга, 23 яшькә кадәрге затларга, алар хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашырган очракта, туендыручысын югалту очрагы буенча пенсиягә социаль өстәмә түләүләр алу хокукын бирү хакында Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министры М.А. Топилинга Пенза өлкәсе Закон чыгару Собраниесе депутатлары мөрәҗәгате турында.

38. Хезмәт пенсияләрен билгеләү өчен иминият стажына хезмәткәрнең 16 яшькә җиткәнче эшләгән чорын кертү турында Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министры М.А. Топилинга Пенза өлкәсе Закон чыгару Собраниесе депутатлары мөрәҗәгате хакында.

39. Муниципаль районнарның шәһәр һәм авыл җирлекләрендә урнашкан сәламәтлек саклау учреждениеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләсе буенча Россия

Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары О.Ю. Голодецка Приморье крае Закон чыгару Собраниесе мөрәҗәгате турында.

40. «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 42 статьясына үзгәреш кертү хакында» 137900-6 номерлы федераль закон проекты турында (конкурста (аукционда) катнашкан өчен җыем билгеләү тәртибе турында).

41. «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү тәртибе турында» Федераль законның 2 һәм 3 статьяларына һәм «Россия Федерациясе закон актларына дәүләт яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләренә хокук алу шартларын һәм тәртибен төгәлләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 137979-6 номерлы федераль закон проекты турында (җир кишәрлекләреннән даими (озак вакытка) файдалану хокукын кабат рәсмиләштерү срогын һәм аларда урнашкан биналарның, корылмаларның, төзелмәләрнең милекчеләре тарафыннан җир кишәрлекләрен ташламалы бәя буенча сату срогын озайту өлешендә).

42. Гамәлдәге законнарга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре өчен электр энергиясен тапшыру буенча хезмәт күрсәтүләргә тарифларны Россия Федерациясе субъектларының региональ үзенчәлекләреннән чыгып электр энергиясен бүтән кулланучылар өчен билгеләнгән дәрәҗәдән үзгә итеп билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А. Медведевка Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесе мөрәҗәгате турында.

43. «Электр энергиясенең ваклап сату базарлары эшчәнлеге, электр энергиясен куллану режимын тулысынча һәм (яисә) өлешчә чикләү турында» 2012 елның 4 маендагы 442 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А. Медведевка Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесе мөрәҗәгате хакында.

44. «Товарлар сатып алулар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә федераль контракт системасы турында» 68702-6 номерлы федераль закон проектына Томск өлкәсе Закон чыгару Думасы тарафыннан әзерләнгән төзәтмәләр хакында.

45. «Дәүләт стратегия планлаштыруы турында» 143912-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

46. «Этил спирты, алкоголь һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм алар әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү турында»

Федераль законның 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Томск өлкәсе Закон чыгару Думасының закон чыгару инициативасы турында.

47. «Тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен саклау һәм алардан файдалану турындагы законнарны бозган өчен җинаять һәм административ җаваплылык турында» СССР Законын Россия Федерациясе территориясендә гамәлдән чыккан дип тану хакында» 4656-6 номерлы федераль закон проекты турында.

48. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 141106-6 номерлы федераль закон проекты турында (тыелган матдәләрне һәм предметларны җәза үтәтү системасы учреждениеләрендә яисә вакытлыча тоту изоляторларында тотылучы затларга тапшырган йә тапшырырга тырышкан өчен җаваплылыкны көчәйтү турында).

49. «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында һәм «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 19 маендагы 86-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 5 пунктының «ж» пунктчасының үз көчен югалтуын тану турында» 142041-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясендә вакытлыча яшәүче чит ил гражданнарын Россия Федерациясендә хезмәт эшчәнлеген башкару өчен эшләүгә рөхсәт алу вазыйфаларыннан азат итү турында, шулай ук югары квалификацияле белгечләр сыйфатында игълан ителгән яисә Россия диңгез суднолары экипажлары составларына җәлеп ителә торган чит ил гражданнарын Россия Федерациясендә хезмәт эшчәнлегенә җәлеп итүгә кагылышлы документларны электрон рәвештә вәкаләтле дәүләт органнарына тапшыру мөмкинлеге турында).

50. «Ирегеннән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны административ күзәтү турында» Федераль законның 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Киров өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

51. «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә салым түләүчеләрнең берләштерелгән төркемнәре һәм үзара бәйле затлар арасында алыш-бирешләр

башкаруга бәйле салым контроле өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 137425-6 номерлы федераль закон проекты турында.

52. «Россия Федерациясе Салым кодексының 208 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 140513-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясендә авторлык яисә катнаш хокукларны файдаланудан алынган керемнәр төрләрен төгәлләштерү өлешендә).

53. Төрлесеннән.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2451-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1498. Ефимов Евгений Петровичның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 пунктының «а» пунктчасы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Бердәм Россия» сәяси партиясеннән бердәм республика сайлау округы буенча сайланган Ефимов Евгений Петровичның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләрен аның депутат вәкаләтләрен туктату турында язма гаризасы нигезендә 2012 елның 30 октябреннән вакытыннан алда туктатылган дип санарга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2452-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1499. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты составындагы үзгәреш турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты составыннан Ефимов Евгений Петровичны чыгарырга.

2. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетын сайлау турында» 2009 елның 19 мартындагы 18-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарының икенче абзацына, «14» санын «13» санына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2453-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1500. Яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру, сәламәт яшәү рәвешен булдыру һәм Казан шәһәрендә уздырылачак 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасын әзерләүгә ярдәм итү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе составындагы үзгәреш турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Ефимов Евгений Петровичны «Яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру, сәламәт яшәү рәвешен булдыру һәм Казан шәһәрендә уздырылачак 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасын әзерләүгә ярдәм итү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе төзү турында» 2009 елның 22 апрелендәге 81-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән расланган Яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру, сәламәт яшәү рәвешен булдыру һәм Казан шәһәрендә уздырылачак 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге

универсиадасын әзерләүгә ярдәм итү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе составыннан чыгарырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2454-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1501. Профессиональ даими нигездә эшләү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатын сайлау турында

«Профессиональ даими нигездә эшләүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары саны турында» 2003 елның 22 сентябрендәге 36-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында профессиональ даими нигездә эшләү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Зарипов Марат Хәй улын сайларга.

2. «Профессиональ даими нигездә эшләү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлау турында» 2009 елның 19 мартындагы 28-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына, өченче абзацта «Ефимов Евгений Петрович» сүзләрен «Зарипов Марат Хәй улы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2455-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1502. «2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 3420-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертелгән «2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 3420-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Әлеге закон проектына төзәтмәләр 2012 елның 9 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2012 елның 29 ноябренә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2456-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1503. «2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 3421-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертелгән «2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 3421-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2012 елның 9 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2012 елның 29 ноябренә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2457-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1504. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 1407-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 1407-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2458-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1505. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (1407-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (1407-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2459-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1506. «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2391-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2391-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты күрсәтелгән закон проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына өченче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2460-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1507. «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 4416-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 4416-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2461-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1508. «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (4416-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (4416-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2462-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1509. «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 6398-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 6398-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты күрсәтелгән закон проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына өченче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2463-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1510. «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 6408-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 6408-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты күрсәтелгән закон проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына өченче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2464-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1511. «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 5417-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 5417-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты күрсәтелгән закон проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына өченче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2465-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1512. «Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу тәртибе турында» 1434-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу тәртибе турында» 1434-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2012 елның 13 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2012 елның 22 ноябренә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2466-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1513. «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 2425-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 2425-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2012 елның 30 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2012 елның 30 декабренә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2467-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1514. «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 4427-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 4427-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2468-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**1515. «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (4427-4 номерлы проект)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (4427-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Әлеге законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2469-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**1516. «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү федераль фондының эконом класслы торак төзелеше өчен, шул исәптән мондый торак төзү максатларында аларны комплекслы үзләштерү өчен түләүсез вакытлыча файдалануга яисә арендага тапшырылган җир кишәрлекләрендә төзелгән яисә төзелеп килүче эконом класслы торакны сатып алу хокукына ия гражданнар исемлекләрен төзү кагыйдәләре турында, әлеге гражданнарны шушы исемлекләргә кертү тәртибе һәм чиратлылыгы турында» 4424-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты тарафыннан кертелгән «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү федераль фондының эконом класслы торак төзелеше өчен, шул исәптән мондый торак төзү максатларында аларны комплекслы үзләштерү өчен түләүсез вакытлыча файдалануга яисә арендага тапшырылган җир кишәрлекләрендә төзелгән яисә төзелеп килүче эконом класслы торакны сатып алу хокукына ия гражданнар исемлекләрен төзү кагыйдәләре турында, әлеге гражданнарны шушы исемлекләргә кертү тәртибе һәм чиратлылыгы турында» 4424-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2012 елның 10 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2012 елның 1 декабренә кадәр

эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2470-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1517. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 5432-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты В.П. Васильев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 5432-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2012 елның 30 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2012 елның 30 декабренә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2471-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1518. «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законының 92 статьясына үзгәреш кертү хакында» 5433-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты В.П. Васильев тарафыннан кертелгән «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законының 92 статьясына үзгәреш кертү хакында» 5433-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2012 елның 30 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2012 елның 30 декабренә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2472-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1519. «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 5437-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты В.П. Васильев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 5437-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2012 елның 30 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2012 елның 30 декабренә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2473-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1520. Татарстан Республикасы административ-территориаль берәмлекләренә исем бирү һәм аларның исемнәрен үзгәртү турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан карау хакындагы нигезләмәнең 18 пунктына үзгәреш кертү турында

«Географик объектлар исемнәре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 10 июлендәге 99-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2011 елның 7 июлендәге 1739-IV ДС номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы административ-территориаль берәмлекләренә исем бирү һәм аларның исемнәрен үзгәртү турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан карау хакындагы нигезләмәнең 18 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:

«4) административ-территориаль берәмлек исемен Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә яисә Татарстан Республикасындагы башка телләрдә гамәлдәге язу рус, татар орфографиясе яисә Татарстан Республикасындагы башка телләр орфографиясе кагыйдәләренә һәм шулай ук күрсәтелгән

телләрдә административ-территориаль берәмлекләр исемнәрен куллану традицияләренә туры килмәсә.».

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2474-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1521. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты составындагы үзгәреш турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты составына Гафуров Илшат Рәфкать улын кертергә.

2. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитетын сайлау турында» 2009 елның 19 мартындагы 19-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарының икенче абзацына, «14» санын «15» санына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2475-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1522. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты составындагы үзгәреш турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты әгъзасы итеп Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Зарипов Марат Хәй улын сайларга.

2. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитетын сайлау турында» 2009 елның 19 мартындагы 17-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

икенче абзацта «13» санын «14» санына алмаштырырга;

өченче абзацта «Ганиев Илшат Газим улы» сүзләреннән соң «Зарипов Марат Хәй улы» сүзләрен өстәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2476-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1523. «Өстенлекле милли проектларны гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссияләре төзү турында» 2006 елның 30 мартындагы 2154-III ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 22 апрелендәге 84-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән расланган Сәламәтлек саклау өлкәсендә милли проектны гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе составындагы үзгәреш турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Өстенлекле милли проектларны гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссияләре төзү турында» 2006 елның 30 мартындагы 2154-III ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 22 апрелендәге 84-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән расланган Сәламәтлек саклау өлкәсендә милли проектны гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан

Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе составына Бикмуллин Альберт Лотфулла улын кертергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2477-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1524. «Муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссияләре әгъзаларын билгеләү турында» 2010 елның 23 сентябрендәге 1127-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарының 1 пунктына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссияләре әгъзаларын билгеләү турында» 2010 елның 23 сентябрендәге 1127-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарының 1 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 8 – 9) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Исланов Роман Леонидович | Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе баш киңәшчесе»; |

2) 4 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Гарипов Илнур Мәхмүт улы | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы»; |

3) 5 пунктчаның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Хәйруллин Инсаф Рәшит улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юллар хуҗалыгы министрының беренче урынбасары»; |

4) 6 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Скворцяков Олег Васильевич | Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы урынбасары»; |

5) 7 пунктчаның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Латыйпов Айрат Камил улы | Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе баш киңәшчесе»; |

6) 8 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге:

| | |
|---|---|
| Малюков Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе баш киңәшчесе; |
| Хафизов Ришат Хәй улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Оештыру идарәсенең җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек итү бүлеге мөдире урынбасары»; |

7) 10 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Әхмәтвәлиев Тимур Дамир улы | Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе баш киңәшчесе»; |

8) 11 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Фәттахов Энгель Нәвап улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры»; |

9) 12 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Кузюров Равил Әфрәһим улы | Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министры урынбасары»; |

10) 13 пунктчаның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Хәкимҗанов Ленар Сәетҗан улы | Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе баш киңәшчесе»; |

11) 16 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Вәлиева Зилә Рәхимьян кызы | «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы директоры»; |

12) 17 пунктчаның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Нефедов Андрей Александрович | Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы урынбасары»; |

13) 18 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ямалниев Илнур Мирзаг улы | Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе баш киңәшчесе»; |

14) 19 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Хәнифов Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары»; |

15) 20 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Зарипов Равил Хаммат улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры»; |

16) 21 пунктчаның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Нуриев Фәнис Галиәхмәт улы | Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе баш киңәшчесе»; |

17) 22 пунктчаның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Гарипов Илнур Мәхмүт улы | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы»; |

18) 23 пунктчаның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Фәхретдинов Булат Альберт улы | Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе баш киңәшчесе»; |

19) 24 пунктчаның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Исаева Анастасия Георгиевна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе урынбасары»; |

20) 27 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Сәхибуллин Айрат Хәдис улы | Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе баш киңәшчесе»; |

21) 28 пунктчаның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Исланов Роман Леонидович | Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе баш киңәшчесе»; |

22) 29 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ильясов Радик Мөдәррис улы | Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча)»; |

23) 30 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Миңнуллин Роберт Мөгаллим улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Татарстан Республикасы законнарының татар һәм рус телләрендәге текстлары тәңгәллеген билгеләү комиссиясе рәисе»; |

24) 31 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Абдуллов Рәфис Харис улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Оештыру идарәсенең җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек итү бүлеге баш белгече»; |

25) 32 пунктчаның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Семенычев Аркадий Борисович | Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе баш киңәшчесе»; |

26) 33 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«33) «Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге:

| | |
|---|---|
| Вәлиев Альберт Мансур улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Оештыру идарәсенең җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек итү бүлеге мөдире |
| Патяшина Марина Александровна | Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе»; |

27) 34 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Шабаев Фәяз Бәян улы | Россия Федерациясенең наркотиклар әйләнешенә контроль буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча)»; |

28) 36 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«36) «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге:

| | |
|---|---|
| Нуретдинов Минсәгыйрь Гайсә улы | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары |

| | |
|---|---|
| Сквордяков Олег Васильевич | Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы урынбасары»; |

29) 38 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Нефедов Андрей Александрович | Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы урынбасары»; |

30) 40 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Белов Александр Николаевич | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты җитәкчесе»; |

31) 41 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Нуриев Фәнис Галиәхмәт улы | Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе баш киңәшчесе»; |

32) 42 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«42) «Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге:

| | |
|---|---|
| Гарипов Илнур Мәхмүт улы | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы |
| Идиатуллин Артур Рево улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Оештыру идарәсе башлыгы»; |

33) 44 пунктчаның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Терентьев Александр Михайлович | Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе»; |

34) 45 пунктчаның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Хәкимҗанов<br>Ленар<br>Сәетҗан улы | Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе баш киңәшчесе». |

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2478-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1525. 2012 елның гыйнварыннан октябренә кадәрге чорда полиция эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министры А.В. Хохорин хисабы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

2012 елның гыйнварыннан октябренә кадәрге чорда полиция эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министры А.В. Хохорин хисабын игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2479-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1526. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 121965-6 номерлы федераль закон проектына төзәтмәләр хакында

Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы тарафыннан беренче укылышта кабул ителгән «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 121965-6 номерлы федераль закон проектын карап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Әлеге закон проектына төзәтмәләрне кабул итәргә һәм аларны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт

Думасының Мәгариф комитетына кертергә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы керткән төзәтмәләрне хуплауны сорап, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте закон чыгару (вәкиллекле) органнарына җибәрергә.

3. Әлеге закон проектына төзәтмәләрне Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында караганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле итеп Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты Гыйльметдинов Илдар Ирек улын билгеләп куярга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2480-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1527. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12.36.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Новосибирск өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12.36.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Новосибирск өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Новосибирск өлкәсе Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2481-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1528. «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы – Корылтаеның закон чыгару инициативасы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы – Корылтаеның закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы – Корылтаена җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2482-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1529. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 381 статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Амур өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 381 статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Амур өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Амур өлкәсе Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2483-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1530. «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 52050-6 номерлы федераль закон проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 52050-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2484-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1531. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясына һәм «Сочи шәһәрендә 2014 елда XXII Кышкы олимпия уеннарын һәм XI Кышкы паралимпия уеннарын оештыру һәм үткәрү турында, тау климаты курорты буларак Сочи шәһәрен үстерү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 14 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 109201-6 номерлы федераль закон проекты турында (проект документациясенә карата дәүләт экспертизасы үткәрелә торган объектлар исемлеген арттыру өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясына һәм «Сочи шәһәрендә 2014 елда XXII Кышкы олимпия уеннарын һәм XI Кышкы паралимпия уеннарын оештыру һәм үткәрү турында, тау климаты курорты буларак Сочи шәһәрен үстерү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 14 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 109201-6 номерлы федераль закон проектын (проект документациясенә карата дәүләт экспертизасы үткәрелә торган объектлар исемлеген арттыру өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2485-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1532. «Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 259 статьясына үзгәреш кертү турында» 136086-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 259 статьясының икенче өлешендә каралган гарантияләрнең ундүрт яшькә кадәрге балаларны ирennән (хатыныннан) башка тәрбияләүче аналарга һәм аталарга кагылу өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 259 статьясына үзгәреш кертү турында» 136086-6 номерлы федераль закон проектын (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 259 статьясының икенче өлешендә каралган гарантияләрнең ундүрт яшькә кадәрге балаларны иреннән (хатыныннан) башка тәрбияләүче аналарга һәм аталарга кагылу өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2486-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1533. «1941 – 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы чорында зыян күргән гражданнарга социаль ярдәм чаралары турында» 40717-6 номерлы федераль закон проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «1941 – 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы чорында зыян күргән гражданнарга социаль ярдәм чаралары турында» 40717-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2487-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1534. «Ерак Себер районнарында һәм аларга тиңләштерелгән җирләрдә эшләүче һәм яшәүче затлар өчен дәүләт гарантияләре һәм компенсацияләр турында» Россия Федерациясе Законының 34 статьясына үзгәреш кертү хакында» 138744-6 номерлы федераль закон проекты турында (Ерак Себер районнарында һәм аларга тиңләштерелгән җирләрдә эшләүче һәм яшәүче, тәрбиягә бала алган гаилә турында шартнамә буенча балага яисә балаларга опеканы яки попечительлекне гамәлгә ашыручы һәм башка түләүле эшчәнлекне башкармаучы, картлык һәм инвалидлык буенча хезмәт пенсияләрен алучы пенсионерларга Россия Федерациясе территориясендә ял итү урынына барып кайту хакын эшләмәүче пенсионерларга түләгән кебек түләү чыгымнарын компенсацияләү хокукын бирү турында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Ерак Себер районнарында һәм аларга тиңләштерелгән җирләрдә эшләүче һәм яшәүче затлар өчен дәүләт гарантияләре һәм компенсацияләр турында» Россия Федерациясе Законының 34 статьясына үзгәреш кертү хакында» 138744-6 номерлы федераль закон проектын (Ерак Себер районнарында һәм аларга тиңләштерелгән җирләрдә эшләүче һәм яшәүче, тәрбиягә бала алган гаилә турында шартнамә буенча

балага яисә балаларга опеканы яки попечительлекне гамәлгә ашыручы һәм башка түләүле эшчәнлекне башкармаучы, картлык һәм инвалидлык буенча хезмәт пенсияләрен алучы пенсионерларга Россия Федерациясе территориясендә ял итү урынына барып кайту хакын эшләмәүче пенсионерларга түләгән кебек түләү чыгымнарын компенсацияләү хокукын бирү турында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2488-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1535. «Россия Федерациясендә 2018 елда футбол буенча ФИФА дөнья чемпионатын, 2017 елда ФИФА Конфедерацияләр кубогын әзерләү һәм үткәрү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 142750-6 номерлы федераль закон проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясендә 2018 елда футбол буенча ФИФА дөнья чемпионатын, 2017 елда ФИФА Конфедерацияләр кубогын әзерләү һәм үткәрү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 142750-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2489-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1536. «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 146690-6 номерлы федераль закон проекты турында (гражданнарны эш белән тәэмин итү категориясенә кертү критерийларын төгәлләштерү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 146690-6 номерлы федераль закон проектын (гражданнарны эш белән тәэмин итү категориясенә кертү критерийларын төгәлләштерү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2490-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1537. Көндез укучы балигъ булмаган балаларга, 23 яшькә кадәрге затларга, алар хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашырган очракта, туендыручысын югалту очрагы буенча пенсиягә социаль өстәмә түләүләр алу хокукын бирү хакында Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министры М.А. Топилинга Пенза өлкәсе Закон чыгару Собраниесе депутатлары мөрәҗәгате турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Көндез укучы балигъ булмаган балаларга, 23 яшькә кадәрге затларга, алар хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашырган очракта, туендыручысын югалту очрагы буенча пенсиягә социаль өстәмә түләүләр алу хокукын бирү хакында Россия Федерация-

се Хезмәт һәм социаль яклау министры М.А. Топилинга Пенза өлкәсе Закон чыгару Собраниесе депутатлары мөрәҗәгатен хупларга.

2. Әлеге карарны Пенза өлкәсе Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2491-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1538. Хезмәт пенсияләрен билгеләү өчен иминият стажына хезмәткәрнең 16 яшькә җиткәнче эшләгән чорын кертү турында Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министры М.А. Топилинга Пенза өлкәсе Закон чыгару Собраниесе депутатлары мөрәҗәгате турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Хезмәт пенсияләрен билгеләү өчен иминият стажына хезмәткәрнең 16 яшькә җиткәнче эшләгән чорын кертү турында Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министры М.А. Топилинга Пенза өлкәсе Закон чыгару Собраниесе депутатлары мөрәҗәгатен хупларга.

2. Әлеге карарны Пенза өлкәсе Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2492-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1539. Муниципаль районнарның шәһәр һәм авыл җирлекләрендә урнашкан сәламәтлек саклау учреждениеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары О.Ю. Голодецка Приморье крае Закон чыгару Собраниесе мөрәҗәгате турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Муниципаль районнарның шәһәр һәм авыл җирлекләрендә урнашкан сәламәтлек саклау учреждениеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары О.Ю. Голодецка Приморье крае Закон чыгару Собраниесе мөрәҗәгатен хупларга.

2. Әлеге карарны Приморье крае Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2493-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1540. «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 42 статьясына үзгәреш кертү хакында» 137900-6 номерлы федераль закон проекты турында (конкурста (аукционда) катнашкан өчен җыем билгеләү тәртибе турында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 42 статьясына үзгәреш кертү хакында» 137900-6 номерлы федераль закон проектын (конкурста (аукционда) катнашкан өчен җыем билгеләү тәртибе турында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Хөкүмәтенә һәм Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2494-IV ДС

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1541. «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү тәртибе турында» Федераль законның 2 һәм 3 статьяларына һәм «Россия Федерациясе закон актларына дәүләт яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләренә хокук алу шартларын һәм тәртибен төгәлләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 137979-6 номерлы федераль закон проекты турында (җир кишәрлекләреннән даими (озак вакытка) файдалану хокукын кабат рәсмиләштерү срогын һәм аларда урнашкан биналарның, корылмаларның, төзелмәләрнең милекчеләре тарафыннан җир кишәрлекләрен ташламалы бәя буенча сату срогын озайту өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү тәртибе турында» Федераль законның 2 һәм 3 статьяларына һәм «Россия Федерациясе закон актларына дәүләт яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләренә хокук алу шартларын һәм тәртибен төгәлләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 137979-6 номерлы федераль закон проектын (җир кишәрлекләреннән даими (озак вакытка) файдалану хокукын кабат рәсмиләштерү срогын һәм аларда урнашкан биналарның, корылмаларның, төзелмәләрнең милекчеләре тарафыннан җир кишәрлекләрен ташламалы бәя буенча сату срогын озайту өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2495-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1542. Гамәлдәге законнарга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре өчен электр энергиясен тапшыру буенча хезмәт күрсәтүләргә тарифларны Россия Федерациясе субъектларының региональ үзенчәлекләреннән чыгып электр энергиясен бүтән кулланучылар өчен билгеләнгән дәрәҗәдән үзгә итеп билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А. Медведевка Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесе мөрәҗәгате турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Гамәлдәге законнарга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре өчен электр энергиясен тапшыру буенча хезмәт күрсәтүләргә тарифларны Россия Федерациясе субъектларының региональ үзенчәлекләреннән чыгып электр энергиясен бүтән кулланучылар өчен билгеләнгән дәрәҗәдән үзгә итеп билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А. Медведевка Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесе мөрәҗәгатен хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Хөкүмәтенә һәм Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2496-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1543. «Электр энергиясенең ваклап сату базарлары эшчәнлеге, электр энергиясен куллану режимын тулысынча һәм (яисә) өлешчә чикләү турында» 2012 елның 4 маендагы 442 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А. Медведевка Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесе мөрәҗәгате хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Электр энергиясенең ваклап сату базарлары эшчәнлеге, электр энергиясен куллану режимын тулысынча һәм (яисә) өлешчә чикләү турында» 2012 елның 4 маендагы 442 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А. Медведевка Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесе мөрәҗәгатен хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Хөкүмәтенә һәм Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2497-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1544. «Товарлар сатып алулар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә федераль контракт системасы турында» 68702-6 номерлы федераль закон проектына Томск өлкәсе Закон чыгару Думасы тарафыннан әзерләнгән төзәтмәләр хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Товарлар сатып алулар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә федераль контракт системасы турында» 68702-6 номерлы федераль закон проектына Томск өлкәсе Закон чыгару Думасы тарафыннан әзерләнгән төзәтмәләрне хупларга.

2. Әлеге карарны Томск өлкәсе Закон чыгару Думасына һәм Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2498-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1545. «Дәүләт стратегия планлаштыруы турында» 143912-6 номерлы федераль закон проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Дәүләт стратегия планлаштыруы турында» 143912-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2499-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**1546. «Этил спирты, алкоголь һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм алар әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү турында» Федераль законның 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Томск өлкәсе Закон чыгару Думасының закон чыгару инициативасы турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Этил спирты, алкоголь һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм алар әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү турында» Федераль законның 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Томск өлкәсе Закон чыгару Думасының закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Томск өлкәсе Закон чыгару Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2500-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1547. «Тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен саклау һәм алардан файдалану турындагы законнарны бозган өчен җинаять һәм административ җаваплылык турында» СССР Законын Россия Федерациясе территориясендә гамәлдән чыккан дип тану хакында» 4656-6 номерлы федераль закон проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен саклау һәм алардан файдалану турындагы законнарны бозган өчен җинаять һәм административ җаваплылык турында» СССР Законын Россия Федерациясе территориясендә гамәлдән чыккан дип тану хакында» 4656-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2501-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1548. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 141106-6 номерлы федераль закон проекты турында (тыелган матдәләрне һәм предметларны җәза үтәтү системасы учреждениеләрендә яисә вакытлыча тоту изоляторларында тотылучы затларга тапшырган йә тапшырырга тырышкан өчен җаваплылыкны көчәйтү турында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 141106-6 номерлы федераль закон проектын (тыелган матдәләрне һәм предметларны җәза үтәтү системасы

учреждениеләрендә яисә вакытлыча тоту изоляторларында тотылучы затларга тапшырган йә тапшырырга тырышкан өчен җаваплылыкны көчәйтү турында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2502-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1549. «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында һәм «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 19 маендагы 86-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 5 пунктының «ж» пунктчасының үз көчен югалтуын тану турында» 142041-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясендә вакытлыча яшәүче чит ил гражданнарын Россия Федерациясендә хезмәт эшчәнлеген башкару өчен эшләүгә рөхсәт алу вазыйфаларыннан азат итү турында, шулай ук югары квалификацияле белгечләр сыйфатында игълан ителгән яисә Россия диңгез суднолары экипажлары составларына җәлеп ителә торган чит ил гражданнарын Россия Федерациясендә хезмәт эшчәнлегенә җәлеп итүгә кагылышлы документларны электрон рәвештә вәкаләтле дәүләт органнарына тапшыру мөмкинлеге турында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында

һәм «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 19 маендагы 86-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 5 пунктының «ж» пунктчасының үз көчен югалтуын тану турында» 142041-6 номерлы федераль закон проектын (Россия Федерациясендә вакытлыча яшәүче чит ил гражданнарын Россия Федерациясендә хезмәт эшчәнлеген башкару өчен эшләүгә рөхсәт алу вазыйфаларыннан азат итү турында, шулай ук югары квалификацияле белгечләр сыйфатында игълан ителгән яисә Россия диңгез суднолары экипажлары составларына җәлеп ителә торган чит ил гражданнарын Россия Федерациясендә хезмәт эшчәнлегенә җәлеп итүгә кагылышлы документларны электрон рәвештә вәкаләтле дәүләт органнарына тапшыру мөмкинлеге турында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2503-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1550. «Ирегеннән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны административ күзәтү турында» Федераль законның 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Киров өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Ирегеннән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны административ күзәтү турында» Федераль законның 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Киров өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Киров өлкәсе Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2504-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1551. «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә салым түләүчеләрнең берләштерелгән төркемнәре һәм үзара бәйле затлар арасында алыш-бирешләр башкаруга бәйле салым контроле өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 137425-6 номерлы федераль закон проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә салым түләүчеләрнең берләштерелгән төркемнәре һәм үзара бәйле затлар арасында алыш-бирешләр башкаруга бәйле салым контроле өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 137425-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2505-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1552. «Россия Федерациясе Салым кодексының 208 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 140513-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясендә авторлык яисә катнаш хокукларны файдаланудан алынган керемнәр төрләрен төгәлләштерү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Салым кодексының 208 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 140513-6 номерлы федераль закон проектын (Россия Федерациясендә авторлык яисә катнаш хокукларны файдаланудан алынган керемнәр төрләрен төгәлләштерү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 30 октябре
№ 2506-IV ДС

# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 1553. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз өченче утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз өченче утырышын 2012 елның 11 октябрендә 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 4 октябре
№ 2387- IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 1554. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз өченче утырышы каравына кертелүче мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утыз өченче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. «2012 елга, 2013 һәм 2014 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

2. «2012 елга, 2013 һәм 2014 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законы-

на үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

3. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

4. «Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 3411-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

5. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2399-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).

6. «Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 4382-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (III укылыш).

7. «Пенсиягә федераль социаль өстәмә күләмен билгеләү өчен Татарстан Республикасында 2013 елга пенсионерның яшәү минимумы күләмен билгеләү турында» 6410-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

8. «Татарстан Республикасы Түбән Кама районы һәм Түбән Кама шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» 2412-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

9. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2377-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (мәгълүмат (документлар, материаллар, мөрәҗәгатьләргә җаваплар) тапшыруның билгеләнгән сроклары вазыйфаи затлар тарафыннан үтәлмәгән өчен административ җаваплылык билгеләү турында) (I укылыш).

10. «Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. «Гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын

гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 2422-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

12. «Ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш керү хакында» 4418-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 5417-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. «2013 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү учреждениеләрендә һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга гражданнарның хокукларына дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 7415-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

15. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 109969-6 номерлы федераль закон проекты хакында (объектны файдалануга тапшыруга рөхсәтләр бирүдән баш тарту өчен нигезләргә өстәмә кертү өлешендә).

16. «Россия Федерациясе гражданлыгы турында» Федераль законның 14 статьясына һәм 32 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 129079-6 номерлы федераль закон проекты турында (чит илдә яшәүче ватандашларыбызның Россия Федерациясенә үзләре теләп күчүләренә ярдәм күрсәтү буенча дәүләт программасы нигезендә яшәү өчен алар сайлап алган Россия Федерациясе субъекты территориясендә тору урыны буенча миграцион исәпкә куелган чит ил гражданнары һәм гражданлыксыз затлар өчен гадиләштерелгән тәртиптә кабул итү нәтиҗәсендә Россия гражданлыгын алу мөмкинлеген бирү турында).

17. «Сайланулы муниципаль вазыйфалар исемлеге киңәюгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 133727-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

18. «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның $25^1$ статьясына үзгәреш кертү хакында» 134114-6 номерлы федераль закон проекты турында (граждан хезмәтендә булу срогын үзгәртү өлешендә).

19. «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законына үзгәрешләр кертү хакында» 134123-6 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт органының конкурс һәм аттестация комиссияләрен төзү тәртибен үзгәртү өлешендә).

20. «Россия Федерациясе Хезмәт кодексына һөнәри стандарт төшенчәсен, аны эшләү һәм раслау тәртибен законнар белән билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 134129-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

21. «Мәгариф турында» Россия Федерациясе Законының 15 статьясына, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 14 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 129241-6 номерлы федераль закон проекты турында (рус ымлыклары телен куллануны җайга салучы нормаларны Инвалидлар хокуклары турында БМО конвенциясе таләпләренә туры китерү өлешендә).

22. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына радиация йогынтысына дучар булган аерым категория гражданнарның сәламәтлегендәге үзгәрешләрне исәпкә алуны тәэмин итү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 114114-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

23. «Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 123 статьясына үзгәреш кертү турында» 104460-6 номерлы федераль закон проекты хакында (14 яшькә кадәрге баласы (балалары) булган хатын-кызга аның өчен уңайлы вакытта ел саен отпуск бирү турында).

24. «Балалы гаиләләргә өстәмә дәүләт ярдәме чаралары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 83634-6 номерлы федераль закон проекты турында (ана (гаилә) капиталы акчаларын инвалид баланы дәвалауга һәм реабилитацияләүгә җибәрү мөмкинлеге турында).

25. «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 17 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 63743-6 номерлы федераль закон проекты турында (инвалид балалары булган гаиләләргә, торак фондының кемгә каравына бәйсез рәвештә, торак урыннар өчен түләүгә ташламалар бирү өлешендә).

26. «Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 331 һәм $351^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 106159-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясе Хезмәт кодексы һәм Россия Федерациясе Җинаять кодексы нигезләмәләре арасында Россия Федерациясе Җинаять кодексыннан 129 һәм

130 статьяларны төшереп калдыруга бәйле рәвештә барлыкка килгән каршылыкларны бетерү турында).

27. «Россия Федерациясе сәламәтлек саклау системасын медицина кадрлары белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А. Медведевка Мәскәү өлкә Думасы мөрәҗәгате хакында.

28. Россия Федерациясендә мәҗбүри һөнәри пенсия системалары турындагы һәм мәҗбүри һөнәри пенсия системаларын финанслауга иминият кертеме турындагы федераль законнар проектларын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына тиз арада кертүнең зарурлыгы хакында Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министры М.А. Топилинга, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга Амур өлкәсе Закон чыгару Собраниесе мөрәҗәгате хакында.

29. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.20 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 77372-6 номерлы федераль закон проекты турында (административ хокук бозулар составын төгәлләштерү өлешендә).

30. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 8.21 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 108677-6 номерлы федераль закон проекты турында (атмосфера һавасын саклау кагыйдәләрен бозган өчен җаваплылыкны көчәйтү турында).

31. «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» Россия Федерациясе Законының 4 статьясына һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 3.5 һәм 13.15 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 109392-6 номерлы федераль закон проекты турында (хокукка каршы гамәлләрдән зыян күргән балигъ булмаган затлар турында мәгълүматны таратуны чикләү өлешендә).

32. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 73982-6 номерлы федераль закон проекты турында (Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.22 статьясы редакциясен төгәлләштерү өлешендә).

33. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.20 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча халык депутатларының Орел өлкә Советы закон чыгару инициатива-

сы турында (алкогольле продукцияне эчү тыела торган урыннар исемлеген төгәлләштерү турында).

34. Хөкүмәт сәгате: «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалауда һәм аларның хокукларын яклауда балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссияләр эшчәнлеге».

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 4 октябре
№ 2388-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 1555. Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру буенча 2013 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының чаралар планы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру буенча 2013 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының чаралар планын расларга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 4 октябре
№ 2390-IV ДС

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының
2012 елның 4 октябрендәге 2390-IV ДС номерлы карарына
кушымта

## Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру буенча 2013 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының чаралар планы

| № т/б | Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы тәкъдимнәр | Гамәлгә ашыру чаралары | Башкару вакыты | Башкару өчен җаваплылар |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Бүгенге икътисадый һәм сәяси үзгәрешләр шартларында икътисадны ныгыту һәм гражданнарыбызның тормыш-көнкүрешен яхшырту бурычлары безнең өчен зур әһәмияткә ия.<br>Республиканың уңышы һәрвакытта да икътисадый күрсәткечләр белән генә түгел, социаль үсешнең, иҗтимагый-сәяси тотрыклылыкның югары дәрәҗәсе белән дә билгеләнеп килде. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының «Татарстан Республикасында куллану кәрзине турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүдә катнашуы. | 2013 ел дәвамында | Социаль сәясәт комитеты |
| 2. | Татарстан Конституциясенең егерме еллыгы Төп законның тарихи әһәмиятен һәм республиканың хәзерге дәүләтчелеген формалаштырудагы ролен ассызыклады. | «Яңа федератив Россия төзү: Татарстан Республикасының конституциячел законнарын булдыру тәҗрибәсе» дигән Халыкара фәнни-гамәли конференциясен оештыру һәм уздыру. | 2012 елның 2 – 3 ноябре | Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3. | Россиянең кайбер төбәкләрендә ризасызлык белдерүләр күзәтелгәндә, Татарстандагы күпчелек граждан житди социаль-икътисадый һәм сәяси проблемаларның урамда хәл ителмәвен яхшы аңлый. Безгә мондый социаль карашларны хуплау мөһим. | Иҗтимагый-сәяси һәм социаль-икътисадый үстерүнең актуаль проблемалары турында фикер алышу, дәүләт сәясәтен булдырганда һәм закон проектлары белән эшләгәндә гражданнарның фикерен исәпкә алу өчен ТР Дәүләт Советында депутат берләшмәләренең, ТР Иҗтимагый палатасының, ТРда «ГХФ» координация советының, «ТЯГ» хәрәкәтенең һәм башка иҗтимагый оешмаларның потенциалын актив куллану. | ел дәвамында | Фракцияләр һәм башка депутат берләшмәләре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |
| 4. | Сәяси партияләр спектры киңәя, аларның җәмгыять тормышында катнашулары арта бара. Демократик процедураларның роле үсә, аларга гражданнар да күбрәк җәлеп ителә. Яңа сәяси чынбарлык формалаша. Боларның барысы да конструктив сәяси көчләрнең, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының, иҗтимагый берләшмәләр һәм массакүләм мәгълүмат чараларының эшендә стимул булып торырга тиеш. Җәмгыятьтәге үзгәрешләргә дөрес җавап бирә белергә, кыю инициативалар белән чыгарга, халыкның төрле төркемнәре белән тигез хокуклы сөйләшүләр алып барырга кирәк. | Экспертлар, югары уку йортлары мөгаллимнәре һәм студентлары, сәяси партияләр һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләрен җәлеп итеп, сәясәт-партия һәм сайлау системасын формалаштыру проблемалары һәм перспективалары буенча «түгәрәк өстәл»ләр уздыру. | ел дәвамында | Фракцияләр һәм башка депутат берләшмәләре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5. | Республика законнарындагы үзгәрешләр иҗтимагый хәрәкәтне төп координацияләү үзәге – Татарстанның Иҗтимагый палатасы ролен күтәрергә ярдәм итәргә тиеш. | Комитетларның закон чыгару эшенә караган планы нигезендә закон проектларын эшләү буенча эшче төркемнәр составында ТР Иҗтимагый палатасы әгъзаларының катнашуын тәэмин итү. ТР Дәүләт Советы депутатларының ТР Иҗтимагый палатасы утырышларында катнашуы. | 2013 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |
| 6. | Мәгълүмат кырында сизелерлек үзгәрешләр бара. Электрон ресурслар һәм социаль челтәрләр «традицион» ММЧга җитди көндәш һәм йогынты ясый алырлык иҗтимагый көч булдылар. | Гражданнарга республика законнарының торышы турында мәгълүмат бирү буенча электрон хезмәтләр күрсәтү максатларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге ТР Дәүләт Советы рәсми сайтына Татарстан Республикасы законнарының җыйма текстларының электрон вариантларын урнаштыру. «Татарстан Республикасы законнарындагы яңалыклар» рубрикасын булдыру, законнарның паспортларын алып бару. | 2013 елның 30 июненә кадәр | ТР Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 7. | Мондый шартларда дәүләт һәм җәмгыять яшьләрнең социаль роленә, аларның дөньяга карашы һәм омтылышына өстенлек бирә. Дәүләт яшьләр сәясәте бу бурычны комплекслы хәл итәргә тиеш.<br>Яшьләрнең иртә социальләшүе, аларның энергиясен ачу һәм иҗади юнәлеш бирү механизмын үстерергә кирәк. | 1. Социаль сәясәт комитетының һәм Яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру, сәламәт яшәү рәвешен булдыру һәм Казан шәһәрендә уздырылачак 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасын әзерләүдә ярдәм итү буенча ТР Дәүләт Советы комиссиясенең берләштерелгән утырышында «Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру хакында» мәсьәләне карау.<br>2. ТР Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр иҗтимагый палатасы чараларын уздыру. | 2013 елның IV кварталы<br><br>2013 ел дәвамында | Социаль сәясәт комитеты, Яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру, сәламәт яшәү рәвешен булдыру һәм Казан шәһәрендә уздырылачак 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасын әзерләүдә ярдәм итү буенча ТР Дәүләт Советы комиссиясе<br><br>ТР Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр иҗтимагый палатасы рәисе |
| 8. | Тарихи-мәдәни мирас елында без матди һәм рухи мәдәният ядкарьләрен саклап калу өчен байтак эшләр башкардык. Яңа музей комплекслары һәм торгызылган объектлар мөһим мәдәни һәм белем бирү үзәкләре булыр.<br>Шуны билгеләп узарга кирәк: бер акция яисә программа кысаларында гына үткәнгә сакчыл мөнәсәбәт булдыру мөмкин түгел. Бу бурыч – мәңгелек. | «Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау эшендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының катнашуы турында» ТР Дәүләт Советы Рәисенең күрсәтмәсен башкаруны тикшереп тору. | 2012 елның IV кварталы | Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 9. | Республиканың дәүләт һәм муниципаль органнары, хокук саклау структуралары, мөселманнарның Диния нәзарәте, «Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына кертелгән үзгәрешләргә таянып, чит идеология үтеп керүгә киртә куярга тиеш.<br>Җәмгыять дини һәм милли экстремизмның теләсә нинди чагылышларына түзеп тормаска тиеш. | 1. «Татарстан Республикасында укытыла торган дини дисциплиналар буенча уку-укыту һәм методик әсбаплар турында» темасына «түгәрәк өстәл» уздыру.<br><br>2. Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты утырышында «Татарстан Республикасында терроризмны һәм экстремизмны профилактикалауга караган законнарны гамәлгә ашыру турында» 2011 елның 15 ноябрендәге 118 номерлы карарын үтәү барышы хакында» мәсьәләсен карау. | 2013 елның I кварталы<br><br>2013 елның марты | Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты<br><br>Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты |
| 10. | «Дини культуралар һәм дөньяви этика нигезләре» уку-укыту курсын гамәлгә ашыру иң нык игътибар бирүне таләп итә. | Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты утырышында Татарстан Республикасындагы мәгариф оешмаларында «Дини культуралар һәм дөньяви этика нигезләре» уку-укыту курсын гамәлгә ашыруның барышы турында ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматын тыңлау. | 2013 елның II кварталы | Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 11. | Безгә төбәкара хезмәттәшлек өлкәсендә дә җентекләбрәк эшләргә кирәк. Бүгенге көнгә Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге 66 субъект белән төзелгән килешү һәм шартнамәләре бар. | ТР Дәүләт Советы депутатларының, комитетларының, Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләренең Россия Федерациясе субъектлары парламентлары белән хезмәттәшлек итүе (аерым план нигезендә). | ел дәвамында | ТР Дәүләт Советы депутатлары, комитетлары, Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләре |
| 12. | Милли сәясәткә килгәндә, монда үзгәртергә ярамаган принципиаль сораулар бар. Сүз, иң элек, дәүләтнең икетеллелеге, шулай ук рус һәм татар телләрен мәҗбүри өйрәнү турында бара. Бу – үзара хөрмәт итүгә корылган милләтара мөнәсәбәтләрне булдыруның һәм республикада тотрыклылыкны саклауның нигезе. | «2004 – 2013 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын башкару нәтиҗәләре турында» мәсьәлә буенча «Хөкүмәт сәгатен» уздыру. | 2013 елның II кварталы | Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 13. | Киләсе елдан нәтиҗәле эшләүче авыл хуҗалыгы предприятиеләренә дәүләт ярдәме принцибын кертү зарур. Актаныш, Балтач, Әтнә, Саба районнарында базар коралларын куллануның уңай тәҗрибәсе бар инде. | Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитетының һәм «2008 – 2012 елларга Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгын үстерү» максатчан республика программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча ТР Дәүләт Советы комиссиясенең берләштерелгән утырышында «2008 – 2012 елларга Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгын үстерү» максатчан республика программасын 2012 елның III кварталында башкаруга йомгак ясау һәм нәтиҗәле эшләүче авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә дәүләт ярдәме турында» мәсьәләне карау. | 2012 елның 23 октябре | Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 14. | Авылга һәм аның халкына ярдәм итү республика өчен өстенлекле бурыч булып кала бирә. Авылда торак, юллар, авыл клубларын, беренчел медицина звеносы учреждениеләрен төзү, мәктәпләрне ремонтлау, газлаштыру буенча республика программаларын, «Чиста су» программасын һәм башка программаларны гамәлгә ашыру дәвам иттереләчәк. | 1. Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты утырышында «Татарстан Республикасында халыкны эчәргә яраклы сыйфатлы су белән тәэмин итүгә юнәлтелгән чаралар турында» мәсьәләне карау. | 2013 елның марты | Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты |
| | | 2. Яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру, сәламәт яшәү рәвешен булдыру һәм Казан шәһәрендә уздырылачак 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасын әзерләүдә ярдәм итү буенча ТР Дәүләт Советы комиссиясе утырышында «Авыл яшьләре белән мәдәният-спортка һәм сәламәтлеккә караган эшне оештыру» мәсьәләсен карау | 2013 елның II кварталы | Яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру, сәламәт яшәү рәвешен булдыру һәм Казан шәһәрендә уздырылачак 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасын әзерләүдә ярдәм итү буенча ТР Дәүләт Советы комиссиясе |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 15. | Республикада гамәлгә ашырыла торган күләмле проектлар кадрлар белән тәэмин ителешкә зур таләпләр куя. Һөнәри яктан әзерләү системасының нәтиҗәлелеген күтәрү мөһим.<br>Икътисад өлкәсендә хәзерге һәм киләчәктә булачак таләпләргә җавап бирердәй кадрларны һөнәргә әзерләү һәм яңа һөнәргә өйрәтү системасын алга таба камилләштерү буенча республика стратегиясе эшләнергә һәм кабул ителергә тиеш. Бу стратегиянең соңгы максаты – эшче белгечләрне әзерләү буенча гына түгел, ә яңа һөнәргә өйрәтү буенча компетенция үзәкләрен төзү. | Социаль сәясәт комитеты утырышында «Татарстан Республикасында яшьләр арасында эшче һәм инженер һөнәрләренең престижын күтәрү максатларында мәгълүмат бирү һәм һөнәргә юнәлтү буенча алып барыла торган эшләрнең нәтиҗәлелеге турында» мәсьәләне карау. | 2012 елның IV кварталы | Социаль сәясәт комитеты |
| 16. | Клиникаларыбызда технологияләр үсә. Инде медицинадагы иң катлаулы юнәлешләр буенча операцияләр ясала. Йөрәк белән бавырны күчереп утырту операцияләре уздырыла. Сәламәтлек саклауның шушы юнәлешен тагы да ныграк үстерү таләп ителә. | Социаль сәясәт комитеты һәм Сәламәтлек саклау өлкәсендә илкүләм проектның тормышка ашырылуын тикшереп тору буенча ТР Дәүләт Советы комиссиясенең берләштерелгән утырышында «Татарстан Республикасында югары технологияле медицина ярдәмен үстерү һәм күрсәтү турында» мәсьәләне карау. | 2013 елның I кварталы | Социаль сәясәт комитеты |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 17. | Без беренчел медицина ярдәмен күрсәтү сыйфатын һәм шартларын күтәрергә тиеш. Беренчел челтәрне яңарту якындагы 5 елда өстенлекле бурыч булырга тиеш. | Сәламәтлек саклау өлкәсендә илкүләм проектның тормышка ашырылуын тикшереп тору буенча ТР Дәүләт Советы комиссиясенең күчмә утырышында «Беренчел медицина-санитария ярдәмен күрсәтүне оештыру турында» мәсьәләне ТР Дәүләт Советы Президиумының 2012 елның 19 апрелендәге 2089-IV ДС номерлы карарында бәян ителгән тәкъдимнәрнең үтәлеше өлешендә карау. | 2012 елның IV кварталы | Социаль сәясәт комитеты |
| 18. | 2013 елгы Бөтендөнья студентлар уеннарына әзерлек кысаларында булдырылган заманча спорт инфраструктурасы, һичшиксез, сәламәт яшәү рәвешен булдыруга яхшы нигез булачак. Универсиада ике атна дәвам итәчәк, әмма аннан соң калган мирас озак еллар дәвамында сәламәтлекне саклау һәм ныгытуга хезмәт итәчәк. | Яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру, сәламәт яшәү рәвешен булдыру һәм Казан шәһәрендә уздырылачак 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасын әзерләүдә ярдәм итү буенча ТР Дәүләт Советы комиссиясе утырышында «Яшәү урынында физкультура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар булдыру турында» мәсьәләне карау. | 2013 елның II кварталы | Яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру, сәламәт яшәү рәвешен булдыру һәм Казан шәһәрендә уздырылачак 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасын әзерләүдә ярдәм итү буенча ТР Дәүләт Советы комиссиясе |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 19. | Уеннарның иминлеген тәэмин итү эшенә иң төп әһәмият бирелә. Бу – хокук саклау органнары эшчәнлегендә өстенлекле юнәлеш. | Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты утырышында «XXVII Бөтендөнья студентлар җәйге универсиадасына әзерлек һәм аны уздыру чорында Казан шәһәрендә юлларның иминлеген тәэмин итү чаралары турында» мәсьәләне карау. | 2013 елның феврале | Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты утырышы |
| 20. | Торак-коммуналь хуҗалык оешмалары эшчәнлегенә муниципалитетлар, республика башкарма хакимият органнары һәм эшчәнлекләрен үзләре җайга салучы оешмалар тарафыннан контроль көчәергә тиеш. | Җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган муниципаль торак контролен булдыру юлы белән торак контролен көчәйтүгә юнәлдерелгән «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү. | 2013 елның I кварталы | Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты |
| 21. | Федераль законнар нигезендә 1 сентябрьдән җылылык энергетикасы тармагында каракаршы субсидияләү бетерелде. Хөкүмәт һәм муниципалитетлар моның социаль зарарын киметү өчен гражданнарыбызга адреслы ярдәм итүне тәэмин итәргә, шулай ук энергетика компанияләренең чыгымнарын һәм аларның инвестиция программалары нәтиҗәлелеген контрольдә тотуны көчәйтергә тиеш. | Чаралар күрү зарурлыгы, шулай ук торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия алуга гражданнарның хокукларын аңлату буенча сайлау округларында эш алып бару. | 2012 елның IV кварталы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 22. | Экологик яктан имин азык-төлек продуктлары җитештерү технологияләрен үстерү юнәлешендә аерым эшләр башкарылды. Республикада калдыклар белән эш итүнең комплекслы системасын булдыруга без зур өметләр баглыйбыз. | Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты утырышында «Калдыклар белән эш итүнең комплексы системасы турында» мәсьәләне карау. | 2013 ноябре | Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты |
| 23. | Урманнарның торышын, аларны саклауны һәм яңартуны, заманча технологияләрдән файдаланып, махсус контрольдә тотарга кирәк.<br>Җирле хакимият органнарының бурычы – республиканың барлык шәһәрләрендә һәм районнарында паркларны торгызу һәм арттыру программалары эшләү һәм гамәлгә ашыруга керешү, халыкны һәм предприятиеләрне төзекләндерү эшләренә күбрәк җәлеп итү. Торак пунктларда халыкка ял итү өчен уңайлы һәм матур урыннар саны артырга тиеш. | Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты утырышында «2018 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасы урман хуҗалыгын үстерү стратегиясен Саба муниципаль районында гамәлгә ашыру барышы турында» мәсьәләне карау. | 2013 елның 3 октябре | Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты |
| 24. | Без дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең гражданнар өчен уңайлы шартлар тудыруга юнәлдерелгән яңа баскычына күчәбез. Агымдагы елның 1 июленнән хакимият органнарының башка дәүләт органнары карамагында булган документларны һәм мәгълүматны гражданнан таләп итәргә хакы юк. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми сайтына («Еш бирелә торган сораулар» бүлегендә) тиешле аңлатулар урнаштыру. | 2013 елның гыйнвары | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 25. | Коррупциягә каршы гамәлләр кылу, икътисадый һәм социаль тармакларда аның чагылышларын профилактикалау буенча максатчан, системалы чаралар таләп ителә. | 1. Керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясен төзү.<br>2. Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты утырышында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарында һәм җирле үзидарә органнарында коррупциягә каршы экспертиза үткәрү турында» комитетның 2011 елның 24 маендагы 59 номерлы һәм 2012 елның 22 маендагы 57 номерлы карарларын үтәү барышы хакында» мәсьәләне карау.<br>3. Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты утырышында «Татарстан Республикасында коррупцияне профилактикалау турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру барышы хакында» комитет карарын үтәү барышы турында» мәсьәләне карау. | до 2013 елга кадәр<br>2013 елның апреле<br>2013 елның июне | Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты<br>Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты<br>Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 26. | Дәүләт һәм муниципаль заказлар урнаштырганда башлангыч бәяләрне, төзелеш-монтаж һәм төзекләндерү эшләре бәяләрен ясалма арттырып күрсәтү, күчемсез милек объектларын һәм җирләрне нигезсез түбән бәягә сату фактларын хәзер инде җитешсезлекләр һәм нәтиҗәсез эшчәнлек дип кенә атап булмый. Бу җинаятькә тиң. Бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалануны арттыру максатларында дәүләт заказы өлкәсендә, сатып алуларда һәркемнең ирекле, ачык һәм тигез хокуклы катнашуын тәэмин итеп, конкурентлылык дәрәҗәсен сизелерлек арттырырга кирәк. | 1. 2013 – 2015 елларга Татарстан Республикасы бюджетын формалаштыру буенча республиканың шәһәр һәм районнары вәкилләре катнашында зона киңәшмәләре үткәрү.<br>2. Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм «Татарстан Республикасы дәүләт заказы, инвестиция эшчәнлеге һәм регионара багланышлар агентлыгы» ДУП белән берлектә «Товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» «түгәрәк өстәл» үткәрү. | 2012 елның IV кварталы<br><br>2013 елның I кварталы | Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты |
| 27. | Муниципаль реформаны гамәлгә ашыру буенча күп эшләр башкарылды. Урыннардагы хакимият органнары үз бурычларын мөстәкыйль үтәү тәҗрибәсе тупладылар һәм идарә өлкәсендә карарлар кабул итүдә кыюрак эш итә башладылар. Җирле үзидарә инициативаларын хуплау практикасын арттырырга кирәк. | «Гражданнарның үз-үзләрен оештыруы өчен шартлар тудыру, территориаль иҗтимагый җирле үзидарәне үстерү буенча Чистай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм депутатлар корпусының уртак эшчәнлеге турында» Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты рәисе В.Н. Липужина һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты В.В. Смыков катнашында матбугат конференциясе үткәрү. | 2013 елның феврале | Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 28. | Җирле үзидарә инициативаларын хуплау практикасын арттырырга кирәк. | «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы белән хезмәттәшлек итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының вәкаләтләре турында» Татарстан Республикасы законы кабул итү. | 2013 елның I кварталы | Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты |

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 1556. Татарстан Республикасы Дәүләт гимны текстының иң яхшы проектына конкурс үткәрү буенча комиссия эшенең барышы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт гимны текстының иң яхшы проектына конкурс үткәрү буенча комиссия рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р.А. Ратникованың Татарстан Республикасы Дәүләт гимны текстының иң яхшы проектына конкурс үткәрү буенча комиссия эшенең барышы турында мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт гимны текстының иң яхшы проектына конкурс үткәрү буенча комиссия эшенең барышы турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт гимны текстының иң яхшы проектына конкурс үткәрү буенча комиссиягә Татарстан Республикасы Дәүләт гимны текстының иң яхшы проектына иҗади конкурс үткәрү буенча эшне дәвам итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 4 октябре
№ 2391-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 1557. Р.Н. Кадыйрованы «Татарстан Республикасының Атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелүгә тәкъдим итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге мөдире вазыйфаларын башкаручы Кадыйрова Рима Назыйф кызын халыкка социаль ярдәм күрсәтүне оештырудагы аерым казанышлары өчен «Татарстан Республикасының Атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелүгә тәкъдим итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 4 октябре
№ 2392-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 1558. З.Х. Хәсәновны «Татарстан Республикасының Атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре» Татарстан Республикасының мактаулы исемен бирүгә тәкъдим итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Эшләр идарәсенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшчәнлеген матди-техник тәэмин итү бүлеге мөдире Зөфәр Хөсәен улы Хәсәновны элемтә чараларының югары сыйфатлы, тоткарлыксыз эшләвен тәэмин итүдәге, инфокоммуникация инфраструктурасы эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттырудагы, принципиаль яңа югары нәтиҗәле технология эшләүдәге һәм аны гамәлгә кертүдәге казанышлары өчен «Татарстан Республикасының Атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә

хезмәткәре» Татарстан Республикасының мактаулы исеменә тәкъдим итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 4 октябре
№ 2393-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 1559. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз дүртенче утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз дүртенче утырышын 2012 елның 30 октябрендә 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 22 октябре
№ 2445-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 1560. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз дүртенче утырышы каравына кертелүче мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утыз дүртенче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. «2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 3420-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

2. «2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 3421-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

3. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 1407-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

4. «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2391-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

5. «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 4416-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

6. «Татарстан Республикасында гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 6398-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

7. «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 6408-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

8. «Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу тәртибе турында» 1434-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

9. «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2425-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

10. «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 4427-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I  укылыш).

11. «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү федераль фондының эконом классны торак төзелеше өчен, шул исәптән мондый торак төзү максатларында аларны комплекслы үзләштерү өчен түләүсез вакытлыча файдалануга яисә арендага тапшырылган җир кишәрлекләрендә төзелгән яисә төзелеп килүче эконом классны торакны сатып алу хокукына ия гражданнар исемлекләрен төзү кагыйдәләре турында, әлеге гражданнарны шушы исемлекләргә кертү тәртибе һәм чиратлылыгы турында» 4424-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

12. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 5432-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

13. «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законының 92 статьясына үзгәреш кертү хакында» 5433-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. Татарстан Республикасы административ-территориаль берәмлекләренә исем бирү һәм аларның исемнәрен үзгәртү турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан карау хакындагы нигезләмәнең 18 пунктына үзгәрешләр кертү турында.

15. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты составындагы үзгәрешләр турында.

16. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты составындагы үзгәрешләр турында.

17. «Өстенлекле милли проектларны гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссияләре төзү турында» 2006 елның 30 мартындагы 2154-III ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 22 апрелендәге 84-IV номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән расланган Сәламәтлек саклау өлкәсендә милли проектны гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе составына үзгәреш кертү турында.

18. «Муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссияләре әгъзаларын билгеләү турында» 2010 елның 23 сентябрендәге 1127-IV

номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында.

19. 2012 елның гыйнварыннан октябренә кадәрге чорда полиция эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министры хисабы.

20. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12.36.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Новосибирск өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

21. «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы – Корылтаеның закон чыгару инициативасы хакында.

22. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 381 статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Амур өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында.

23. «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 52050-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

24. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясына һәм «Сочи шәһәрендә 2014 елда XXII Кышкы олимпия уеннарын һәм XI Кышкы паралимпия уеннарын оештыру һәм үткәрү, тау-климат курорты буларак Сочи шәһәрен үстерү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 14 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 109201-6 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт экспертизасы үткәрелә торган проект документациясенә карата объектлар исемлеген арттыру өлешендә).

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 22 октябре
№ 2446-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 1561. Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре вазыйфаларына кандидатларны алдан сайлап алу турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре вазыйфаларына кандидатларны алдан сайлап алу турындагы хәбәрнамә текстын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре вазыйфаларына кандидатуралар турындагы тәкъдимнәрне берләштерергә һәм 2012 елның 15 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Дәүләт Советына бәяләмә тапшырырга тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 22 октябре
№ 2448-IVДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Президиумының
2012 елның 22 октябрендәге
2448-IVДС номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре вазыйфаларына кандидатларны алдан сайлап алу турында хәбәрнамә**

«Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре турында» 2003 елның 11 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары вазыйфаларына кандидатларны алдан сайлап алуның башлануы турында игълан итә.

Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары вазыйфаларына кандидатларны алдан сайлап алу тәртибе турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2003 елның 20 февралендәге 1898 номерлы карары белән расланган нигезләмәнең 4 пунктында (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2007 елның 28 сентябрендәге 3102-III ДС номерлы карары ред.) күрсәтелгән тиешле документлар әлеге хәбәрнамә басылып чыккан көннән унбиш көн эчендә түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 420060, Казан шәһәре, Ирек мәйданы, 1 йорт, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 1562. «Татарстан Республикасында гражданнарның хезмәт хокукларын яклау турында» темасына парламент тыңлаулары уздыру хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетына 2012 елның 21 ноябрендә 14.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кече утырышлар залында «Татарстан Республикасында гражданнарның хезмәт хокукларын яклау турында» темасына парламент тыңлаулары уздыруны йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 22 октябре
№ 2449-IVДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 1563. 45 нче Апас бермандатлы сайлау округы һәм 47 нче Кукмара бермандатлы сайлау округы буенча дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын өстәмә сайлаулар, Татарстан Республикасы аерым муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле органнары депутатларын өстәмә сайлаулар йомгаклары турында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе Ә.С. Гобәйдуллинның мәгълүматы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

45 нче Апас бермандатлы сайлау округы һәм 47 нче Кукмара бермандатлы сайлау округы буенча дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын өстәмә сайлаулар, Татарстан Республикасы аерым муниципаль

берәмлекләренең вәкиллекле органнары депутатларын өстәмә сайлаулар йомгаклары турында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе Ә.С. Гобәйдуллинның мәгълүматын игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 22 октябре
№ 2450-IVДС